СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*24 июль, 1998 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 83 (8240)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# КАБУЛ ИТ, ТАТАРСТАН, НУРЛАТ ИКМӘГЕН!



***Чәршәмбе көнне Нурлат элеваторына быелгы уңышның беренче ашлыгын төягән машиналар килде. Иң кадерле йөк төялгән олаулар Мичурин исемендәге, “Татарстан”, “Кондырча”, Рассвет” һәм Хафизов исемендәге хуҗалыклардан иде. Беренче ике хуҗалык элеваторга көзге бодай, калганнары арыш китерде.***

***Уракка да, ашлык хәзерләүгә дә республикада беренчеләрдән булып керешкән игенчеләребезгә сабырлык һәм куанычлар телибез.***

*(Бу вакыйга һәм шул ук көнне булган башка тантаналар турында газетабызның иртәгәге санында тәфсилләп язачакбыз).*




***Фәнис Талиповичның төп һөнәре - укытучы. Югары белемгә ия булып кайтканнан соң Биккол авылы егете озак кына Фома урта мәктәбендә балаларны хезмәткә, җир эшкәртүдә төп техника - тракторны өйрәнергә, яратырга өйрәтә. Анда ук һөнәренә гашыйклыгы тирән, киң кырлы белеме белән укучыларның хөрмәтен казана. Ул әзерләгән укучылар хәзер туган кырларында тырышып эшлиләр. Аннары шул ук профиль буенча 99нчы СПТУда эшен дәвам итә. Ләкин Нурлатка күчеп кенә авыл белән бәйләнешен югалтмый, җәй җиттеме ул зур теләк белән кышкы һөнәрен алмаштыра: район МТСы комбайннарында хуҗалыклар кырларына урып - җыюга чыгып китә. Инде механизатор һөнәре буенча да шактый тәҗрибә тупларга өлгергән Ф.Гаязов, былтыр районга “Кейс”лар кайткач, үз - үзенә нык ышанып шатланып әлеге комбайнга утырды. Быел беренче урак көнен Мичурин исемендәге хуҗалыктан башлады, бу фоторәсеме дә шундагы арыш кырыннан.***

***Рәсемдә: “Кейс” комбайнчысы Фәнис Гаязов.***

***Н.АЗИЗОВ фотосы.***

## КАЙДА КҮПМЕ ҖИР БАР?

***ТРның Министрлар Кабинеты карары нигезендә, өченче ел инде район торак пунктларын инвентаризацияләү бара.***

Быел бу эш белән ике группа шөгыльләнә. Беренчесе - “Волга НИИгипнозем” институтының Татарстан филиалы белгечләре килешү буенча Әлмәт кустында эшлиләр. Алар Кычытканлы авылында инвентаризация үткәрделәр инде, хәзер Иске һәм Яңа Әлмәт авыллары җирләрен үлчәү белән мәшгульләр. Икенче группа - җир ресурслары һәм җир реформалары буенча район комитеты каршындагы “Кадастройбюро” вәкилләре (җитәкчесе Ф.Ф.Алякимов) - шундый ук эшне Биләр Озеро кустында алып баралар. Биләр Озеро, Зирекле авылларында инвентарьлаштыру төгәлләнде инде, хәзер эш Чулпанда дәвам итә.

Ә инвентаризацияләү - җитди һәм зур җаваплылык сорый торган хезмәт. Районда 84 торак пункт 5 меңнән артык гектар җирне били. Инвентаризация үткәрүчеләр һәр торак пункт җирләрен төгәл үлчәп, 1 : 2000 масштабы буенча планга салырга, аларны әлегәчә булган мәгълүматлар белән чагыштырырга, шулай итеп, Җир милкенә Дәүләт акты бирүгә әзерләргә тиешләр. Район җир комитеты белгечләре, әлбәттә, берочтан җирләрнең ничек файдаланылуына да игътибар бирәләр.

Инвентаризацияне тулысынча 1999 елда төгәлләргә ниятлиләр.

## ПРОСПЕКТ ЯҢАРА

Шәһәрнең төньягында калкып чыккан Карл Маркс проспектына да, ниһаять, үзгәрешләр килеп җитте. Шушы көннәрдә генә биредә килү юлларына, йорт каршыларына һәм мәйданчыкка асфальт түшәлде. Күптармаклы җитештерү предприятиесе заявкасы нигезендә бу эшләрне “Татнефтедор” акционерлык җәмгыятенең Нурлат автоюллар идарәсе башкарды. Прораб М.М.Вәлиев җитәкчелегендә юл төзүчеләр 1200 кв. метр мәйданның нигезен әзерләү, аңа асфальт - бетон түшәү эшләрен бик кыска срокта башкардылар.

## БҮГЕНГӘ ПЕНЯ КҮЛӘМЕ ТҮБӘНРӘК

РФның дәүләт салым службасы карары нигезендә салым инспекцияләре үзвакытында түләнмәгән салым бурычларына тәүлеклек пеня салуны яңа система буенча алып барачаклар.

Әлегә кадәр пеня билгеләнгән күләмдә, бурычның 0,3 процентына үсә иде, ә хәзер ул үзәк банк куйган процент ставкасына бәйләнгән һәм үзгәртеп финанслау ставкасы дип аталачак. Бүген район салым инспекциясе хезмәткәрләре 1нче апрельдән салым бурычларына җыелган пеняны яңадан хисаплау буенча киеренке эш алып баралар. Элеккеге хисаплар буенча 1нче апрельгә бюджетка (бюджеттан тыш фондларга бурычлар пенясы әлегә элеккечә кала) түләнмичә калган барлык пеня күләме 67025 мең сум булса, яңадан хисаплаудан соң ул сизелерлек кимегән, ягъни 13405 мең сум тәшкил итә. Дөрес, юридик затлар өчен бу яңалык куанырлык төсле, ләкин беренче карашка гына, чөнки банк ставкаларын үзгәртеп тора, ул зуррак булган саен пеня күләме дә югарырак булачак.

**БҮГЕНГЕ САНДА:**

- **Беренче олаулар;**
- **Кырларга сак карыйк;**
- **Бораулаучылар конференциясендә;**
- **КВН. Белдерүләр.**

*Берләштерелгән советта*

## “ТӘРТИП ОЕШТЫРУЧЫЛАРДАН БАШЛАНА”

Ел саен җәйге чорда халык терлекләренең басуларга зыян китерүе кискен мәсьәлә булып тора. Быел да хәл үзгәрмәгәнгә күрә, хакимият башлыгы тарафыннан үткәрелгән киңәшмәләрдә чәчүлекләрне терлекләрдән саклау бурычлары турында җитәкчеләргә кат - кат искәртергә туры килә. Нурлат берләштерелгән Советының авыл җирле үзидарәләре Советлары җитәкчеләре катнашындагы чираттагы киңәшмәсендә дә шул мәсьәлә кузгатылды һәм кырларның терлекләрдән зыян күрү фактлары мисалга китерелде. Шунда ук Нурлат берләштерелгән Советы рәисе урынбасары А.Н.Ельченков басуларны саклауга тиешле игътибар бирмәгән Советларның исемнәрен атады. Алар аеруча Биләр Озеро, Егоркино, Иске Әлмәт, Кычытканлы, Әмзә советлары. Киләчәктә дә басуларны саклауга салкын караш күзәтелгән очракта җаваплы кешеләргә карата тиешле чаралар кулланылачагы искәртелде.

Киңәшмәдә, гомумән, дисциплина, һәр эшкә җитди мөнәсәбәт булдыру турында сүз зур урын алды. Бу советларга кергән территорияләрне төзекләндерү, чисталыкта тоту кебек һәрдаим сөйләнелә торган эшләрнең һаман җиренә җиткерелмәвенә дә бәйләнгән иде.

Шулай ук авыл кешеләренең йортларына газ кертүне тизләтү бурычы да алгы планга куелды.

Авыл юлларында хәрәкәт куркынычсызлыгы мәсьәләләре дә кискен тора. Бу хакта киңәшмәдә юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча дәүләт инспекциясе начальнигы Х.В. Әюпов сөйләде. Аның әйтүенчә, авыл юлларында исерек хәлдә транспорт белән идарә итүчеләр саны артканнан - арта бара, нәтиҗәдә көненә 2 - 3 һәлакәт очрагы теркәлеп тора, иң кызганычы, алар кеше гомере өчен фаҗигале тәмамлана. Шунда ук шәхси транспортны теркәү мәсьәләләре дә кискен куелды һәм аларның исемлеген төзү бурычы рәисләргә йөкләнде.

*Балаларның җәйге ялы*

## АНАПАДАН ХӘБӘР БАР

***Район хакимиятенең яшьләр бүлеге телефон аша хәбәрләшеп диңгез буенда ял итүче балаларыбызның хәлен белешкән.***

Безнең төркем исән - сау барып җитеп урнашкан. Көн дәвамында егет - кызларыбыз җирле хуҗаларга ярдәм йөзеннән 1 - 2 сәгать буена шәфталу һәм слива җыялар икән. Ә тәүлекнең калган вакыты махсус төзелгән план буенча диңгез ярында ял итү, шәһәрдәге музейларга экскурсияләргә бару, тауларга йөрү һәм башка төрле шөгыльләр белән үтә ди. Төркем җитәкчесенең әйтүенчә, балалар бик канәгать. Кичке сәгать 8.00 дән 10.00га кадәр һәр көнне дискотека үткәрелә. Нәкъ менә шушы иркен арада безнең Нурлаттан теләгән кешегә шалтыратырга да мөмкин дигәннәр, балаларның үзләрен телефонга чакырырга вәгъдә иткәннәр. Газизләренең тавышын сагынучылар рәхим итсеннәр!

## ҖИТӘКЧЕ АЛЫШЫНДЫ

20 июль көнне “Чирмешән” КХАсы әгъзаларының гомуми җыелышы булды. Җыелыш шәхси гаризасы нигезендә сәламәтлеге торышы буенча КХА рәисе Х.Ш.Шәмсуаровны вазифаларыннан азат итте. “Чирмешән” КХАсы рәисе итеп **Рәис Таһир улы ГАТАУЛЛИН** сайланды.

Җыелышта район хакимияте башлыгының беренче урынбасары, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Ф.М.Дәүләтшин, хакимият башлыгы урынбасары Н.Х.Абдуллин һәм хакимиятнең аппарат җитәкчесе Ф.Р.Ногъманова катнаштылар.

## ЯКТАШЫБЫЗГА - МАКТАУЛЫ ИСЕМ

ТР Президенты Указы белән “Татмелиорация” траст компаниясе” ачык акционерлык җәмгыятенең мелиорация һәм су хуҗалыгы дирекциясе директоры - якташыбыз **Юрий Васильевич АНИСИМОВка “Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы”** дигән мактаулы исем бирелде.

## Хезмәт коллективларында җыелышлар

# ЙӨК БЕРГӘ ТАРТКАНДА ГЫНА ҖИҢЕЛ

Җәмгыять директоры А.С.Насолдинның беренче яртыеллыктагы эшчәнлек турында отчет докладында теге яки бу күрсәткечләрне "НУРБ чагында" һәм "бүлентекле хәлдә" дигәнрәк ике чорга аерып атау еш булды. Анысы аңлашыла да, чөнки элеккеге Нурлат разведка бораулавы идарәсе былтыр җаваплылыгы чикләнгән "Татнефть - Нурлатнефтеразведка" бүлентекле җәмгыяте булып оешты. Мондый структураның күпмедер дәрәҗәдә уңай яклары булса да, мөстәкыйльлек, бигрәк тә финанс мәсьәләләрендәге мөстәкыйльлек ягыннан караганда, бораулаучыларның хокуклары барыбер тарая төшкән. Аның каравы, Нурлат бораулаучылары, базар мөнәсәбәтләренә яраклашып, үзәк предприятие "Татнефть"тән тыш алты мөстәкыйль заказчы белән дә эш итәләр. Менә быелның беренче яртысында да барлыгы 56.138 метр тау токымы бораулаңган булса ( бу - узган елның шул чорына карата 114,3 процент), шуның яртысына якыны гына - "Татнефть" заказы буенча. Файдалануга бирелгән 36, шул исәптән узган елгыдан икегә артыграк скважинаның да 16сы - башка заказчылар өчен. Базар шартларында кем акчалы - шуңа эшлисең, анысы ачык аңлашыла, һәм Нурлат бораулаучылары да андый мөстәкыйль заказчыларның киләчәктә ике - өч тапкыр артасына өметләнәләр. Тик менә эчке базарда исәп - хисапның 80 процентка кадәре бартер рәвешендә баруның гына үз кыенлыклары бар.

Әмма бораулаучыларның хезмәте, күпсанлы кыенлыкларга да карамастан, алда телгә алынган абсолют саннардан тыш, нәтиҗәлелекнең үсә баруы, җитештерүчәнлекнең күтәрелүе белән дә характерлана. Әйтик, бораулау бригадаларында долотога туры килә торган проходка былтыргы 126 метр урынына быел 152,5 метр тәшкил иткән. Мең метр токымны тишеп үтүгә китә торган вакыт ике тапкырга диярлек кимегән. Дөрес, бораулау бригадаларының төп эш күрсәткечләре арасында аермалар ярыйсы гына һәм нәкъ менә шул зур аермаларны бетерү максатыннан оешмада бригадаларны һәм цехларны кече хуҗалык исәбенә күчерү эше бара. Икенче төрле әйткәндә,теге яки бу скважинаны бораулауга, яки башка төр эш күләмен башкаруга смета буенча күпме чыгым тотылырга тиешлеген санап бирәләр дә, бригада шул чыгымнарга сыеша икән, бер төрле хезмәт хакы ала, ә аларны янга калдыруга ирешсә, янга калдырылган акчаның билгеле бер өлеше шул коллективка өстәп языла. Бораулау бригадаларының эш күрсәткечләре арасындагы чуарлык, шул ук вакытта хезмәт хакларындагы аермалар да аларның файдаланылмаган мөмкинлекләре шактый булуын ачык раслый. Бригадалар буенча уртача рентабельлелек 11,5 процент булса, кайсыларында ул 22 проценттан да югары, шул ук вакытта зыянга эшләгән бригадалар да бар. Җәмгыять директоры автотрактор цехында да хезмәт хакын башкарылган эш күләме белән тәңгәл китерү юнәлешендә эшлисе барлыгына басым ясап үтте.

Һәркемнең эш хакы аның керткән өлешенә бәйле булырга тиешлеге җәһәтеннән җәмгыятьтә быел белгечләр һәм инженер - техник хезмәткәрләр чираттагы аттестация үткән һәм аның нәтиҗәләре шактый ук уйландырырлык булып чыккан. Ә инде хезмәтне оештыру, аңа түләү системасын камилләштерү һәм башка мәсьәләләрдә беренче сүзне әйтергә тиешле кайбер белгечләрнең икътисадый белеме чамалы булу күп нәрсә турында сөйли.

Җәмгыять директоры, эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү юнәлешендә файдаланылмаган резервларның болардан тыш та шактый булуын телгә алып, моннан ары коллективны, эш күләмен һ.б. саклап калу өчен төп ике - тар, бер генә юнәлешле калып камилләшү яки башка төр эшләр дә үзләштереп, продукция һәм хезмәтләр белән базарга чыгу юллары барлыгына һәм бораулаучыларга шул ике юлның да уңышлы якларын сайлап алып эш итәргә кирәк буласына басым ясады. Ул яктан Нурлат бораулаучыларының былтыр шәһәрне эчә торган су белән тәэмин итү буенча гаять мөһим зур заказ башкарганлыкларын беләбез инде, алга таба да көймәләре кырыс базар диңгезенең давыллы дулкыннарында югалып калмас дип ышанасы килә. Өстәвенә, Нурлат бораулаучылары коллективының күптәннән килә торган һәм ныклы традицияләре дә, шул традицияләрне эзлекле дәвам иттерүче хезмәт династияләре дә бар. Шул ук вакытта монда эшләгән кешенең кадерен дә беләләр. Җәмгыять директоры да хезмәтне саклауга, эш шартларын камилләштерүгә күп чыгымнар тотылуы турында әйтеп үтте. Күмәк килешүне үтәүнең барышы турында мәгълүмат ясаган профсоюз комитеты рәисе Г.Ш. Сөләйманов та нигездә ул килешү буенча эшләүчеләрнең матди мәнфәгатьләрен кайгыртуга бәйле пунктларның ничек үтәлүенә тукталды. Дөрес, нефть базарындагы кыенлыклар матди кызыксындыру һәм социаль түләүләрне соңгы вакытта шактый чикләргә мәҗбүр иткән. Әмма эшчеләрне буровойларда хезмәт хакы исәбенә һәм арзанрак бәягә тукландыру кебек мөһим нәрсә саклана әле һәм анысыннан баш тартырга уйламыйлар. Тик менә соңгы вакытта болай да административ ялларның кем күпмете шулай бирелүенә карамастан, хезмәткә яраксызлыкның аерым төрләре буенча айлар буе эшләмәүчеләрнең күплеге, шул ук вакытта аларның шактыеның, предприятиедә хезмәтне һәм хезмәт кешесенең сәламәтлеген саклау юнәлешендә тиешле шартлар һәм мөмкинлекләр тудырылуга карамастан, шуны санга сукмаучылар булуы гына зур борчу тудыра. Һәм бу мәсьәлә киләчәктә администрациянең дә, профсоюз комитетының да аерым игътибарында булырга тиеш дип басым ясалды җыелышта.

Әйе, йөк ике як таҗитәкчелек тә, эшчеләр дә бергә җигелеп тартканда гына җиңел шул, һәм предприятиенең нәтиҗәлелеге, бүгенгесе һәм иртәгәсе турында да һәркемнең башы авыртса гына яхшы.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

# ХӘЛГӘ КЕРЕП, ЧАМАНЫ БЕЛЕП...

Сугыш һәм хезмәт ветераннары район Советы президиумының күптән түгел булып үткән утырышында Бөек Ватан сугышы инвалидларын һәм анда катнашучыларны льготалы яки бушлай рецептлар буенча дарулар белән тәэмин итү мәсьәләсе каралды.

Соңгы айларда хастаханә кассасы һәм район бюджетыннан финанслау буенча тоткарлык килеп чыгуы нәтиҗәсендә районда бу җәһәттән хәл кискенләште. Район хастаханә кассасы аптекага 460 мең сум, ә район бюджеты 60 мең сум бурычлылар. Нәтиҗәдә аптека бушлай рецепт буенча сугыш ветераннарына дарулар бирүне вакытлыча туктатты.

Әлеге мәсьәлә район хакимияте башлыгының финанс мәсьәләләре буенча урынбасары Ф.Н.Гобәйдуллин үткәргән киңәшмәдә каралды. Барлык медицина хезмәтләре җитәкчеләре һәм салым инспекциясе вәкилләре катнашындагы бу киңәшмәдә сугышта катнашучыларны бушлай дарулар белән тәэмин итү турында конкрет карар кылынды.

Ветераннар оешмасы һәм район хакимияте бу фактны ризасызлык белән кабул иттеләр, чөнки республиканың башка районнарында һәм Россия өлкәләрендә мондый күренешләр гадәти хәлгә әйләнсә дә,әлегә кадәр районда безнең бушлай рецептларга дарулар бирмәү очрагы булганы юк иде.

Ай саен район аптекасы бушлай рецептлар буенча 35 категориядәге авыруларга 100 меңнән күбрәк сумлык дарулар биреп тора. Бу авыр вакытта да ул онкологик авыруларга һәм диабеттан интегүчеләргә дару бирүне туктатмады. Һәм бу нигезле дә.

Медицина учреждениеләренең, район бюджетының финанс хәлен исәптә тотып, район Советы ветераннардан бу мәсьәләгә төптән уйлап якын килүне һәм иң кирәкле даруларны гына яздыруны үтенә.

**И. ГЫЙЛӘҖЕВ,**
**сугыш һәм хезмәт ветераннарының район Советы рәисе.**

## МИКУШКИННАРНЫҢ БЕРСЕ



Биләр Озерода Микушкиннарның фамилиясе күренекле. Кайсын гына атасаң да - Владимирмы, Михаилмы, Александрмы - хуҗалыкта яхшы исәптәге, тырыш һәм булдыклы кешеләр. Рәсемдә хезмәт юлының күп өлешен трактор бригадасы бригадиры булып узган Владимир Прокофьевич сурәтләнгән. Үз гомерендә аңа 9 җитәкче белән эшләргә туры килә. Кем вакытында уңайрак иде, дип сорагач ул: "Барысы да эшләгәнне яраталар иде",- дип җавап бирә үз - үзенә ныклы ышаныч белән.Гаилә башлыгы буларак балаларын да шундый рухта тәрбияли - улы Александр да авылда тракторда эшли, үзенә бирелгән вазифаны җиренә җиткереп үти.

Хәзер Владимир Прокофьевич трактор бригадасында слесарь эшләрен башкара; гади итеп әйткәндә, техниканың төзеклеген тәэмин итүдә аның өлеше аз түгел. Әле менә терлек азыгы хәзерләү вакытында да аның механизаторларга күп ярдәме тиде.

**Фотохәбәрчебез Наил АЗИЗОВ аны нәкъ шул көннәрдә эш урынында төшереп алган.**

## Балаларның җәйге ялы

# ЧИРМЕШӘН БУЕНА НИ ҖИТӘ?!

***Кара диңгез буе үзенчә матурдыр, бәхәсләшмибез. Ә менә "Заречный" лагеренда ял итүче балалар өчен көннең кызулыгы 40тан арткан бу көннәрдә безнең Чирмешәннән кадерлерәк һәм матуррак берни юктыр дөньяда!***

Лагерьдан коену урынына кадәр яшел хәтфә сукмак сузылган, барган чакта үрелеп кенә өзәрдәй биеклектә шомырт тәлгәшләре асылынып тора. Ә коену урыны һичнинди пляжларга биргесез - яр буеның кайнар комы табаннарны кытыклый! Теләсәң күмелеп үк ят комга, теләсәң утыр гына. Елганың коена торган җирендә керергә рөхсәт ителгән ераклык махсус аркан белән билгеләнгән. Ә су төбендә янә дә шул бәрхет ком җәелгән. Җитәкчеләре генә "усал": суда озак булырга кушмыйлар, сәгатькә карап кына торалар . Коенып чыгуга лагерьга кайтучыларны парлы мунча көтә. Салган киемнәрне юып эләргә дә махсус урыннар бар. (Юеш һавада кер киптерү өчен дә җайланма бар монда!) Ә ашханәдә хуш исе урамга ук таралган тәмле ризык әзер.

Лагерьда 130 бала ял итә. Алар 9 отрядка бүленеп урнашканнар. Биналарда һәркайда чисталык - пөхтәлек күзтелә. Лагерьның көндәлек газетасы уңганнарга да, ялкауларга да үзенең сүзен вакытында җиткерә килә. Рәсем конкурслары үткәрәләр, уенсыз, җыр - биюсез бер көн дә узмый монда. Әле узган атнада гына Нурлат тамашачыларын сөендергән цирк коллективы лагерьда да чыгыш ясаган. Лагерьның ачылу тантанасында зур дуслык учагы яккан булганнар. Балыкчы көнендә бәйрәм оештырганнар. Менә шулай яшиләр "Заречный"да.

"Туклану мәсьәләсен хуҗалыклар белән завод арасында үзара исәп - хисап ясау тәртибендә хәл итәбез. Завод җитәкчелеге һәр гозеребезгә игътибарлы",- ди лагерь башлыгы Тәлгать Әгъзам улы Мингазиев. Бу көнне район санэпидкүзәтү үзәге белгечләре дә лагерьга килгәннәр иде. Алар монда көнаралаш диярлек булалар икән. Таләпчән табиблар да лагерь эшеннән канәгать булуларын белдерделәр. Бердәнбер җитешмәүчәнлек - иң гади, иң кирәкле дарулар, дәвалау чаралары булмаудан гаҗизлек иде. Махсус шәфкать туташы билгеләгәннәр. Әмма йөрәк өянәге, хәл китү очраклары була калса - дарулар, хәтта энә кадаганчы тәнне сөртер өчен спирт булмауны санэпидкүзәтү үзәге табиблары да ассызыклап әйттеләр.

Ә гомумән алганда, лагерьда чисталык, тәртип, көнкүреш өчен кирәкле шартлар кайгыртылган, ризык әзерләүчеләр тәҗрибәле һәм намуслы, тәрбиячеләр махсус хәзерлекле һәм булдыклы, ризык тәмле һәм туклыклы, урын - җир чиста. Балалар үзләре дә бик канәгать. Дөрес, боларның һәммәсен шушы дәрәҗәдә оештыруның күпме хезмәт бәрабәренә төшүен завод җитәкчелеге үзе генә беләдер инде. Әмма районыбызда бүгенге шартларда сакланып калган бердәнбер зур ял лагерен киләчәктә дә саклыйсы иде бит. Узган ял көннәрендә балаларның хәлен белергә лагерьга кунакка килгән әти - әниләр дә шушы сүзне хуплыйлар.

**К.ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

*Моны белү кирәк*

# ЯҢА ЗАКОН КАБУЛ ИТЕЛДЕ

***Күптән түгел генә Россиянең үзәк газеталарында РФның 1998 елның 6 мартында Дәүләт Думасында кабул ителгән һәм 1998 елның 27 маенда РФ Президенты кул куйган "Хәрби хезмәткәрләрнең статусы турында"гы яңа законы басылып чыкты.***

"Хәрби хезмәткәрләрнең статусы турында"гы 1993 елда кабул ителгән закон заман таләпләренә җавап бирми башлады, ягъни әхлакый яктан искерде.

Ә яңа Федераль закон РФ Конституциясе нигезендә хәрби хезмәткәрләрнең хокукларын, ирекен, бурычларын һәм җаваплылыгын билгели, шулай ук хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын социаль яклау буенча да дәүләт сәясәтенә нигез булып тора.

Бу законда күпләрне борчый торган сорауларга җавап табарга мөмкин. Яңа законда хәрби хезмәткәрләрнең ирекен, намусын һәм дәрәҗәсен яклау, яшәү урынын сайлау һәм күченү ирегенә, сүз ирегенә хокук, җыелышларда, митингларда, демонстрацияләрдә, пикетларда катнашу хокукы, дин тоту һәм вөҗдан иреге, дәүләт белән идарә итүдә катнашу хокукы, хезмәткә һәм ялга, торакка, сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокуклар, милеккә һәм салымнар буенча ташламалар, страховой гарантияләр һәм китерелгән зыянны каплату хокукы, белемгә хокук һәм мәдәният өлкәсендә хокуклар, азык - төлек белән һәм әйберләтә, акча белән тәэминатка һәм сәүдә - көнкүреш хезмәте күрсәтү хокукы, юридик ярдәм алуга һәм нотариаль гамәлләр кылуга хокук каралган.

Шулай ук гадәттән тыш шартларда һәм кораллы бәрелеш очракларында хәрби хезмәт вазифаларын башкаручыларга өстәмә льготалар, гарантия һәм компенсация бар.

Шундый киң күләмле хокуклар һәм ирек бирү белән бергә закон хәрби хезмәткәргә гомуми вазифага бәйле һәм махсус бурычлар да, шулай ук хокук тәртибен бозулар өчен җаваплылык та билгели.

Бу закон 1998 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керде һәм хәзер аның тулы куәтенә эшләвен һәм файда китерүен генә телисе кала.

**И.ХАФИЗУЛЛИН,**
**район хәрби комиссары урынбасары, подполковник.**

## ИГЕННӘРГӘ ЯНГЫН ТИМӘСЕН

Авыл хезмәтчәннәренең иң кызу чагы - урак өсте җитте. Бар уңышны югалтуларсыз җыеп алу никадәр мөһим булган кебек, аны уттан саклау да шулкадәр әһәмиятле, чөнки игеннәрнең бик тиз янучан булуын тәҗрибә күрсәтте инде: алардан ялкын кабынып зур янгынга әйләнү өчен комбайн, трактордан төшкән очкын, тәмәке төпчеге дә җитә. Йөзләгән кешенең хезмәте санаулы минутлар эчендә җилгә очарга мөмкин, тагын да аянычрагы - йөзләгән тонна кыйммәтле бөртекнең юкка чыгуы ихтимал. Шуңа да уракка катнашучы һәркем җаваплы кампания башланганчы ук янгынга каршы инструктаж үтәргә, урып - җыю агрегатларын һәм автомобильләрне янгын сүндерү чаралары белән җиһазландырырга (комбайннарның һәм тракторларның барлык төрләрендә дә ике ут сүндергеч, икешәр көрәк һәм чиләк булдыру), төзек очкын сүндергечләр һәм көйле кабызу, майлау системалары булдырырга тиешләр.

Башаклар өлгергәнче үк урманга, автомобиль һәм тимер юлларына якын урнашкан иген басуларының кырыйлары 4 метр киңлектә сөрелергә тиеш. Бөртекләрне күләме 50 гектардан артмаган кишәрлекләргә бүлеп урып - җыю хәерле. Шул бүленгән участоклар арасында 8 метрдан тар булмаган үтеп йөрү юлы ясарга кирәк. Игенне тезмнәрдән тизрәк җыеп, тезмнәр уртасында 4 метрдан да ким булмаган җирне сөрү дә мөһим.

Янгын чыгу очрагын күздә тотып урып - җыю барган җирдән ерак түгел сабаны белән трактор тоту да зыян итмәс. Кырларда учак ягу һәм иген сабакларын яндырудан тыелып торырга кирәк.

Янгынга каршы барлык чаралар үтәлгән очракта гына игенне уттан саклап калу мөмкин булачак.

**В.ЕРЕПОВ,**
**янгын күзәтчелеге инспекторы.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Кара Күл авылында яшәүче **Минфатыйх Сәетгәрәй улы Әхмәтовка** 25 июльдә 60 яшь тула. Аны туган көне белән котлыйбыз һәм исәнлек - саулык, аяз күкләр, озын гомер теләп калабыз.

**Кода - кодагые, улы - килене һәм оныклары.**

Нурлат шәһәрендә яшәүче **кадерле әниебез Фәнүзә Әһлиуллинаны** туган көне белән котлыйбыз. Әниебезгә озын гомер, бәхет, сәламәтлек, җан тынычлыгы телибез.

Син бит, әни, өйнең яме,
Ә тормышта олы бер терәк.
Җиргә кояш ничек кирәк булса,
Син дә безгә шулай бик кирәк.

**Әниең, Рәмис, Гөлчәчәк, Рамил, Гөлия.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР

"Таттелеком" электр элемтәсе идарәсе дәүләт унитар предприятиесен хосусыйлаштыру барышында оештырыла торган акционерлык җәмгыяте акцияләренә ябык язылуны әзерләү максатында Нурлат район электр элемтәсе үзәге түбәндәге кешеләрне мәгълүматларны ачыклау өчен паспорт һәм хезмәт кенәгәсе белән тиз арада 1998 елның 28 июленә кадәр килергә чакыра:

- шушы предприятиедән, шул исәптән эштә имгәнү һәм һөнәри авыру аркасында инвалидлык буенча пенсиягә чыккан пенсионерларны;
- шушы предприятиедә кимендә 10 ел эшләп үз теләге белән яки бүтән оешмага күчерү тәртибендә киткән ир - ат һәм кимендә 7 ел ярым (гомуми стаж) эшләп чыккан хатын - кыз хезмәткәрләрне;
- шушы предприятиедә эшләп производствода үлүчеләрнең мирас иясе булып торган гаилә әгъзаларын.

Белешмәләр өчен тел.: 2-27-17.

**Администрация.**
**Профсоюз комитеты.**

## РӘХМӘТЕБЕЗ ИРЕШСЕН

Авыруны берәү дә теләп алмый. Ә инде кинәт кенә чир аяктан екса, табиблар каршына барырга туры килә. Ярый ла шундый авыр минутларда рәхимле, башкаларның кайгысын үзенекедәй күңеленә якын алган ак халатлы шәфкать ияләре очрап торса. 77 яшьлек әниебез Хәдичә Мингалим кызы Әюпованың күзләренә катаракта булгач нәкъ шундый кешеләр белән очрашырга туры килә. Нурлат районы үзәк хастаханәсе күз табибы М.Г.Галиев аның күзенә операция ясаганнан соң әниебез аңа рәхмәт укудан туктамый. Гомумән, ул бүлектә эшләүче шәфкать туташлары, санитаркаларга да һәркайсына олы рәхмәт җиткерә. Шул ук рәхмәтләр һәм җылы теләкләр Бикүле авылыннан Миннегаян Вәлиевадан да барып ирешсен иде. Хөрмәтле, ак халатлы кешеләр, үзегезгә сәламәтлек һәм эшегездә уңышлар телибез.

**Р.ӘЮПОВА.**
**Аксубай районы Яңа Дума авылы.**

***Йорт түбәләреннән яңгыр үтүгә шикаятьләр күбәюне исәпкә алып, торак-коммуналь хуҗалыгы МППсында күмәк антенналар урнаштыру буенча бригада оештырылды. Шул уңайдан, күп фатирлы йортларда яшәүчеләрнең барысының да шәхси антенналарын түбәдән алуларын үтенеп сорыйбыз. Бу эш эшләнмәгән очракта, түбәләр шул йортларда яшәүчеләр хисабына ремонтланачак.***

**"Нур" кибете аз күләмдә түмәрләп азык - төлек продуктлары:**
- тавык ботлары, сосискилар, краб палочкалары;
- балык һәм ит консервлары;
- сыра, сулар һәм соклар;
- макарон һәм кондитер әйберләре;
- чәй, кофе, үсемлек мае, серкә, куертылган сөт, дөге һәм карабодай ярмасы;
- сигаретлар тәкъдим итә.

**Бик арзан, ташламалар ясала.**
**Безнең адрес: Совет ур., 148 (УТТ янында).**
**Тел.: 2-28-32.**

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Самара өлкәсенең Нефтегорск шәһәрендәге яхшыртылган планировкалы ике бүлмәле фатирны (балконы, лоджиясы, дачасы , гаражы бар) - Нурлатта шуңа тиңгә.** Тел.: 5-44-23, 65-5-96.

***

**Өч бүлмәле фатирны - ике берәр бүлмәлегә, шикәр заводыннан һәм тимер юл ягыннан тәкъдим итмәскә.**
Адрес: Степан Разин ур., 4- 2, кичке 5тән соң.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Йомшак мебель ремонтлыйбыз.**
Тел.: 5-19-80.

***

**Кечкенә балалы гаиләгә бер бүлмәле фатир кирәк.** Тел.: 2-21-69.

***

**Өч айга ике бүлмәле фатир кирәк. Бик яхшы хак түләүне гарантиялим.** Тел.: 5-39-29, 5-39-30 (эш).

***

**Гыйматдинов ур., 120 - 18 адресы буенча телефоны булган ике бүлмәле фатирны сатам яки биреп торам.** Тел.: 5-24-51.

**Нурлатта бизәү материаллары һәм сантехника җиһазлары сату буенча махсуслашкан беренче "Интерьер Плюс" кибете яңалыклары.**

Сез өегезгә ремонт ясарга булдыгызмы? Сезгә сантехника, обойлар, линолеум кирәкме? Алар артыннан Самарага яки Казанга барып йөрү ерак та, кыйммәткә дә төшә.

***Үзегезгә кирәкле һәр нәрсәне Сез нәкъ менә безнең кибеттән таба аласыз. Хәлегездән килерлек бәяләрдә бездә 120 төрле обой, 10 төрдә линолеум һәм күп кенә башка әйберләр бар! Аларны бездән алу уңайлы да, файдалы да.***

Зур әйберләрне һичнинди өстәмә түләүсез өегезгә илтеп бирәбез.

Әгәр дә Сез аеруча нәзберек зәвыклы кеше һәм без тәкъдим итә торган товарлар сезгә хуш килми икән, бер дә борчылмагыз, нәкъ менә шундый сатып алучылар өчен бездә товарларның гаять зур төсле каталогы бар. Аннан үзегезнең күңелегезгә хуш килгән әйберне сайлап аласыз да, заказыгыз бер атна эчендә үтәләчәк.

***Сатып алучы канәгать икән, без дә шат.***

"Интерьер Плюс" кибете, Мәктәп урамы, 8нче йорт, икенче кат. Б - 97 сер. № 288649 лицензия.

## БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Чанада 1мм.лы цинкланган калай белән тышланган гараж.** Адрес: Мәскәү ур., 7 - 51, кичке 7дән соң.

***

**1994 елгы ВАЗ - 2121 "Нива".** Тел.: 5-39-08.

***

**Ашыгыч төстә Әфган поселогында төзелеп бетмәгән йорт (мунчасы, төзү материаллары бар).** Тел.: 5-14-79.

***

**Бер бүлмәле фатир.**
Адрес: К.Маркс ур., 4 - 8, тел.: 5-13-77.

***

**Нигез блоклары.** Адрес: Энгельс ур., 27.

***

**Совет ур., 49 - 1 адресы буенча йорт.** Тел.: 2-24

***

**Декабристлар урамында каралтылары белән 70нче йорт.** Тел.: 5-21-86, 2-21-74.

***

**Шәһәр үзәгендәге өч катлы йортның өченче катында ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2-29-15.

***

**ВАЗ - 2105**. Тел.: 5-26-39.

***

**Тимер юлчылар бистәсендә иске йорт, чанада гараж, кыйммәт түгел.**
Адрес: Совет ур.,139 - 5, кичке 7дән соң.

***

**Ике бүлмәле фатир.**
Адрес: Козлов ур., 5- 4, тел.: 2-17-14, кичке 8дән соң.

***

**Өч бүлмәле фатир.** Адрес: К.Маркс ур., 6 - 42, тел.: 5-17-04 (кичке 8дән соң), 2-23-51 (теләсә кайчан).

***

**Алтыпочмаклы йорт, мунчасы бар.**
Тел.: 5-17-04 (кичке 8дән соң), 2-23-51 ( теләсә кайчан).

***

**1996 нчы елгы ВАЗ-21061 һәм 547нче ПМК ягында базы белән капиталь гараж.** Тел.: 5-38-40.

### Хөрмәтле сатып алучылар!

**Универмаг бүлекләрендә сез азык - төлек чекларына кием - салым, аяк киемнәре, буяу, йорт җиһазлары, суыткычлар һәм кер юу машиналары сатып ала аласыз. Сатуда киң ассортиментта базарныкыннан түбәнрәк бәядә уку - язу әсбаплары да бар.**

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Йорт ике бүлмәле фатирга алмаштырыла яки сатыла.**
Куйбышев ур., 78 "а" -1 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 31 нче июль һәм 14нче август көннәрендә, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2337 данә. 2989